**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 елның 20 марты № 172

2024-2025 уку елына Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы территорияләренә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларын беркетү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү уку-укыту программалары буенча укырга кабул итү тәртибен раслау турында» 2020 елның 2 сентябрендәге 458 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы территорияләренә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларын кушымта нигезендә беркетергә.

2.Кама Тамагы муниципаль районының дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә муниципаль районның гомуми белем бирү оешмаларына беркетелгән территорияләрендә яшәүче төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү оешмаларында укырга тиешле балаларны исәпкә алуны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә,шулай ук башлангыч гомуми белем бирүнең төп гомуми белем бирү программалары буенча укытуга өстенлекле кабул итү хокукын абыйлар һәм (яки) апалар укыган муниципаль белем бирү оешмаларына бирергә

3. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы территорияләрендә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларын беркетү турында» Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 15 февралендәге 124 номерлы карарын үз көчен югалткан дип таныргга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Е.В. Сороковнинага йөкләргә.

Җитәкче Р. М. Заһидуллин

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2024елның 20 мартындагы №172 карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы территорияләренә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларын беркетү**

| № т/б | Гомуми белем бирү оешмасының исеме | Беркетелгән территория |
|---|---|---|
| 1. | Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Кама Тамагы урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ | Кама Тамагы штп, Уразлы авылы, Сатлыган авылы |
| 2. | Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Фәйзрахман Сәләх улы Юнысов исемендәге Кама Тамагы татар урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ | Кама Тамагы штп, Бәрлегуҗа, Малаевка, Кече Карамалы, Кече Салтык, Яшелчә, Олы Карамалы , Олы Салтык , Келәр авыллары |
| 3. | Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлегенең «Тәмте урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ | Тәмте , Лабыш , Рус Буртасы, Тукай, Ясная Поляна, Ясная Звезда авыллары, Ирекле Хезмәт поселогы, Татар зона сынау станциясе поселогы, Варварино авылы, Осинники поселогы |
| 4. | Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле урта гомуми белем бирү мәктәбе" МБМУ | Каратал , Иске Казиле авылы, Атабай, Бишалаб, Кыртапа, Кече Бортас, Иске Барыш, Олы Бортас , Балчыклы, Көрәле, Келәнче , Бәки авыллары |
| 5. | Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге "Олы Кариле урта гомуми белем бирү мәктәбе" МБМУ | Олы Кариле, Бәби, Кече Кариле, Шапкә, Чаллы, Балтач, Олы Яңасала авылы, Олы Мәрәтхуҗа , Даныш, Менгличево авыллары |
| 6. | Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш ш.т.п. "Рудник урта гомуми белем бирү мәктәбе" МБМУ | Тенеш штп, Кече Мәрәтхуҗа , Антоновка авыллары |
| 7. | Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөкәй авыл җирлегенең "Сөкәй урта гомуми белем бирү мәктәбе" МБМУ | Сөйки авылы, Сөйки Кичүе поселогы, Мордва Каратае, Ишем авыллары |
| 8. | Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Василий Петрович Муравьев исемендәге Затон урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ | Куйбышев Затоны штп |
| 9. | Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Красновидово төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ | Красновидово авылы |
| 10. | Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельский авыл җирлегенең "Кирельский төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ | Кирельский авылы |

| | | |
|---|---|---|
| 11. | Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Көрәле башлангыч мәктәп-балалар бакчасы» МБМУ | Көрәле авылы |
| 12. | "Советлар Союзы Герое Чирков Михаил Алексеевич исемендәге Кама Тамагы кадет интернат-мәктәбе»ГБОУ | Куйбышев Затоны штп |